**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 февраль № 60

г. Казань

2017 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләме турында

Татарстан Республикасы Президентының «2017 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2017 ел, 1 февраль, ПУ-90 нчы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елда мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президентының түбәндәге грантларын (алга таба – грантлар) билгеләргә:

«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Татар опера һәм балет театрының дөньякүләм музыкаль киңлеккә интеграциясенең яңа этабы: дөньякүләм һәм милли музыкаль театры шедеврларны популярлаштыру, матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, халыкара фестивальләр, гастрольләр һәм проектлар үткәрү, театр спектакльләрен тудыру һәм аларда катнашу өчен сәхнә осталарын чакыру» проекты өчен – 155 800,0 мең сум;

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенә – «Иҗат проектларын тормышка ашыруда инновацион якын килү, Россия һәм чит ил татарларын театр хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү, матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, заманча татар драматургиясен һәм мәдәниятен популярлаштыру, Россия һәм ерак чит илләрнең әйдәп баручы театр коллективлары белән иҗади тәҗрибә алмашу» проекты өчен – 36 360,0 мең сум;

«В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Дөнья әдәбияты әсәрләре нигезендә спектакльләр кую, театр сәнгатен пропагандалауга юнәлтелгән иҗади проектларны тормышка ашыру, Россия һәм ерак чит илләрнең театр коллективлары белән тәҗрибә алмашу» проекты өчен – 26 360,0 мең сум;

«Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Коллективның иҗади потенциалына булышлык күрсәтү,

матди-техник базаны яңарту һәм ныгыту, милли сәнгатьне популярлаштыру, саклау һәм үстерү» проекты өчен – 4 240,0 мең сум;

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә «Музыка һәм сүз сәнгате аша балалар аудиториясен һәм өлкән аудиторияне җәлеп итү һәм тәрбияләүнең уңай дөньякүләм тәҗрибәсе буларак концертларның филармония абонемент системасын эшләү, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 8 798,0 мең сум, «Музыкаль мәдәниятләр һәм дөнья халыклары традицияләре синтезы буларак джаз» проекты өчен – 8 400,0 мең сум, «Россия һәм дөнья халыклары музыкаль мәдәниятенә сәхнә аша татар музыкаль фольклорын тикшерү, пропагандалау һәм интеграцияләү» проекты өчен – 6 700,0 мең сум;

«Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенә «Осталыкны үстерү һәм россия һәм дөньякүләм танылган башкаручылар һәм дирижерларны җәлеп итү» проекты өчен – 12 720,0 мең сум;

«Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Ислам дөньясының яңа киносы чагылышы буларак Казан халыкара мөселман киносы фестивале» проекты өчен – 1 929,2 мең сум;

«Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Керәшен этник музыкаль мәдәнияте һәм милли традицияләренең иң яхшы үрнәкләрен торгызу, саклау, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 2 601,2 мең сум.

2. 2017 елда 263 908,4 мең сум күләмендә грантларны түләү чыгымнары «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

бер ай эчендә грант алучылар тарафыннан грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчаны максатчан файдалану һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисаплар бирү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

2018 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2017 елда грантларны максатчан файдалану турында хисап тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\60.docx